| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.07.2021 991

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2022 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 1 декрабендәге 1356 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «2018-2020 елларга коррупциягә каршы көрәшнең Милли планы турында» 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы Указы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2021 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 1 декабрендәге 1356 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карар исемен «2015-2021 еллар» сүзләрен «2015-2024 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. карарның 1 пунктында «2015-2022 еллар» сүзләрен «2015-2024 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

2. «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Садыйкова Э.И.) әлеге максатларга җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
16.07.2021 № 991
карарына 1 нче кушымта

# «2015-2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы

Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2015-2024 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының хокук палатасы |
| Программаның максаты | Максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру. |
| Программаның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү.<br>2. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен шартлар тәэмин итү.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре үткәрү юлы белән коррупциянең торышын бәяләү.<br>4. Коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү.<br>5. Муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачык булуын, һәркем өчен ачык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру.<br>6. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү.<br>7. Эшкуарлыкка административ басымны эзлекле рәвештә киметү (бизнес-структуралар).<br>8. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру. |

<table>
<tr><td></td><td>Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру срогы (вакыты):</td><td>2020-2024 еллар</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән Программаны финанслау күләмнәре</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме Алабуга муниципаль районы бюджеты хисабына 512,45 мең сум тәшкил итә:
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>73,0</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>39,8</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>49,75</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>49,9</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>50,0</td></tr>
<tr><td>Программа буенча барлыгы</td><td>512,45</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Алабуга муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре</td><td>Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2024 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эчке контролен һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән өлеш е- 100 процентка җитәчәк;<br>коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив хокукый актларның аларның проектларын эшләү стадиясендә өлеше -100 процентка җитәчәк;<br>квалификация күтәрүне узган дәүләт граждан (муниципаль) хезмәткәрләре өлеше ел саен кимендә 33 процентка җитәчәк;<br>коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | хезмәткәрләр өлеше һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләре кимендә 50 процентны тәшкил итәчәк;<br>дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән гражданнарның канәгать булу дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>районда «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләргә керү мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә кимендә 90 процентка җитәчәк;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары рәсми сайтларының бүлекләрен урнаштыруга һәм тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карары белән расланган закон һәм таләпләр нигезендә үзенең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итү өлеше-90 процентка җитәчәк;<br>муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекнең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процентны тәшкил итәчәк. |

## Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә гомуми характеристика. Төп проблемалар һәм аларны хәл итү.

Коррупция хакимиятнең нормаль эшләвенә, закон, демократия, кеше хокуклары һәм социаль гаделлеккә реаль куркыныч тудыра. Шул рәвешле, хәзерге Россиядә коррупция милли куркынычсызлыкка һәм дәүләт яшәешенә янаучы иң кискен проблемаларның берсе булып тора.

Коррупция дәүләтнең һәм җәмгыятьнең социаль-икътисадый үсешенә тискәре йогынты ясый, көндәшлеккә сәләтле икътисад формалаштыруда киртә булып тора, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүгә, үсеш алган граждан җәмгыяте аякка басуга каршылыклар тудыра.

Программа федераль дәрәҗәдә гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы көрәш чаралары системасы белән концептуаль яктан бәйле һәм муниципаль дәрәҗәдә коррупциягә каршы эшне оештыруда программа-максатчан методны куллануның алшартларын тудыра.

Әлеге коррупциягә каршы органнарның һәм җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларның эш сыйфатының активлашуы һәм күтәрелүе күзәтелә.

Алдагы коррупциягә каршы программалар чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗә сендә коррупциягә каршы эшчәнлектә граждан җәмгыяте институтларының ролен арттыру билгеләнә. Шулай итеп, җәмәгатьчелек вәкилләре коррупциягә каршы тору комиссияләре, җирле үзидарә органнары каршындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссияләре составына кертелгән. Яшьләр иҗтимагый оешмалары һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары коррупциягә каршы эшчәнлекнең актив катнашучылары булдылар, һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, җәмгыятьтә коррупцион тәртипкә карата түземсезлек формалаша.

## 2. Программаның максаты һәм төп бурычлары. Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау. Программаның соңгы нәтиҗәләре, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру.

Программаның максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү;

- муниципаль норматив-хокукый актларга һәм муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыруны оештыруны камилләштерү;
- коррупциягә каршы мониторинг уздыру;
- коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;
- дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачык булуын, һәркем өчен ачык булуын тәэмин итү, аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;
- дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны оештыру һәм уздыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү;
- эшкуарлыкка административ басымны эзлекле рәвештә киметү (бизнес-структуралар);
- хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек нәтиҗәлелеген арттыру;
- көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны көчәйтү;

Программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- коррупцияне китереп чыгара торган сәбәпләрне бетерү һәм аның чагылышына каршы торучанлык;

- гражданнар җәмгыятен Алабуга муниципаль районына коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруга җәлеп итү;

- коррупциячел гамәлләргә, күренешләрнең барлык фактларына карата түземсезлек формалаштыру;

- төрле категориядәге җинаятьләрне ачуның иң характерлы үрнәкләрен күрсәтеп.коррупция юнәлешендәге җинаятьләрне профилактикалауның торышын һәм нәтиҗәләрен мониторинглау.

Программаны гамәлгә ашыру срогы (вакыты): 2021-2024 еллар.

Төп максат, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук программада каралган чараларны финанслау күләмнәре Программаның кушымтасында тәкъдим ителде.

Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән 2015 - 2024 елларда 512,45 мең сум тәшкил итә.

| Ел | Алабуга муниципаль район ( мең сум). |
|---|---|
| 2015 | 73,0 |
| 2016 | 39,8 |
| 2017 | 49,75 |
| 2018 | 49,9 |
| 2019 | 50,0 |
| 2020 | 50,0 |
| 2021 | 50,0 |
| 2022 | 50,0 |
| 2023 | 50,0 |
| 2024 | 50,0 |
| Программа буенча барлыгы | 512,45 |

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга Алабуга муниципаль районы җирле бюджет проектын формалаштырганда, Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә бюджетлары мөмкинлекләреннән чыгып, билгеләнгән тәртиптә ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы.

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты Программаның үтәлешен

планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне заказчы - программаның координаторы гамәлгә ашыра, ул ел саен программа чараларының максатчан күрсәткечләрен һәм чыгымнарын аныклый, аны гамәлгә ашыру механизмы һәм башкаручылар составы, чараларны үтәү өчен җаваплы башкаручылардан программаны үтәүнең барышы турында белешмәләр соратып ала.

Программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чараларны финанслау җирле үзидарә органнары, аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы оешмалар һәм учреждениеләр аша гамәлгә ашырыла.

Программаны үтәүчеләр, гамәлгә ашыру өчен җаваплы, квартал саен Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына (дәүләт заказчысы координаторына), хисап чорыннан соң килә торган айның 25 числосына кадәр тиешле бюджетлардан чараларны башкару турында һәм чараларны үтәүчеләргә тиешле бюджетлардан бүленә торган акчаларны үзләштерү турында мәгълүмат бирәләр, аларның нәтиҗәләре арта бара һәм тулаем хисап елында.

Программаны гамәлгә ашыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба - еллык хисап) Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты, хисап чорыннан соң килүче елның числосына кадәр Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә тапшыра.

Еллык хисапка түбәндәгеләр керә:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;
- билгеләнгән срокта башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;
- программаны тормышка ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;
- чаралар башкаруга бюджет ассигнованиеләреннән һәм башка акчалардан файдалану турындагы күрсәткечләр;
- һәм башка мәгълүмат.

Программага үзгәрешләр кертү Программаның чараларын җаваплы башкаручы йә билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен үтәү өчен гамәлгә ашырыла.

## 5. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның гомуми нәтиҗәлелеге билгеләнгән максатчан параметрларга ирешү дәрәҗәсе буенча 2024 елга планлаштырылган, каралган чараларны билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыру буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре, шулай ук Программа башкаручыларының агымдагы хисаплылык материаллары кулланыла.

Программа чараларын уңышлы үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерергә;

- Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы сәясәтен координацияләү нәтиҗәлелеген арттырырга;

-мониторинг тикшеренүләр уздыру, мондый каршылыкның инновацион технологияләрен эзләү һәм кертү ярдәмендә коррупциягә каршы тору һәм коррупциягә каршы көрәш процессларын һәм тенденцияләрен объектив бәяләүне тәэмин итәргә;

коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, кадрлар, матди, мәгълүмати һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итәргә;

- дәүләт һәм муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттырырга;

- эшкуарлык (бизнес) өчен административ басымын киметергә;

-муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы үз-үзләрен тотышын стимуллаштырырга.

Моннан тыш, программа чараларын комплекслы үтәү районда коррупциягә каршы институтларны үстерүгә һәм ныгытуга ярдәм итәчәк. Коррупциягә каршы белем камилләшәчәк. Коррупциягә каршы тематика буенча квалификация күтәрү курсларын узган муниципаль хезмәткәрләр саны артачак.

Программаның социаль эффекты гражданнар үзләренең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тулысынча тормышка ашыруда бәяләнә.

Программаның үзенчәлеген исәпкә алып, туры икътисадый нәтиҗәне билгеләү мөмкин түгел, чөнки программа чаралары гади статистик үлчәүләргә бирелми һәм бәяләр бәяләвендә чагылмый. Шул ук вакытта Программа чараларын гамәлгә ашыруның турыдан-туры икътисадый нәтиҗәсе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының җәлеп итүчән имиджын формалаштыру, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек, эшкуарлык активлыгын күтәрү, районда җирле үзидарә органнарында коррупция чагылышларына бәйле бюджет югалтуларын киметү нәтиҗәсендә күзәтелергә мөмкин.

Программада эшчәнлекнең нәтиҗәләрен характерлаучы индикаторлар һәм күрсәткечләр системасы кулланыла. Программаның эффективлыгын бәяләү аны тормышка ашыруның бөтен чоры өчен 2024 елгы күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып, Программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча үткәрелә.

**«2015 - 2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программаның максатлары, бурычлары, чаралары һәм нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары**

| | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | | | | | Җирле бюджет (АМР | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2013 ел (база елы) | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел |
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |
| | | | Максат: коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү, аның күренешләренә каршы тору, җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формала | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | 1 нче бурыч Коррупциягә каршы тору инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | | | | | | | |
| ль норматив хокукый актларга зендә норматив хокукый актлар | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының эчке контролен һәм коррупциягә каршы механизмны кадрлар сәясәтенә керткән өлеше-процент | 94 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - |
| ча җирле үзидарә органнары эше өчен җаваплы кадрлар<br><br>ı һәм Татарстан Республикасы ıеге юнәлеш буенча кадрларның принцибын ЭBB8DB00353BEE8TBkAHconsul | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| әш турында керемнәр, чыгымнар, | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| актердагы йөкләмәләре:<br><br>на хәбәр итү | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| чикләүләрне һәм тыюларны, шул әм «индивидуаль эшкуарларның ›ыннан файдаланып, эшмәкәрлек | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| хезмәткәрне коррупциячел хокук ны тикшерү | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| ыкка килә торган коррупциячел белән бәйле муниципаль хезмәт | җирле үзидарә органнары (килешү (килешү буенча), хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм АМР мәнфәгатьләре конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча) | ел саен | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| аммаларын коррупция һәм башка ләргә кертелгән затлар һәм әлеге ит илләрдә), транспорт чаралары, реле торган керемнәр, чыгымнар, һәм автоматлаштырылган анализ (граждан-хокукый шартнамәләр) хезмәт күрсәтүгә) вазыйфаларны ıерым функцияләре муниципаль артнамәсе шартларында вазыйфа | АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча), АМР Советының Кадрлар хезмәте (килешү буенча) | Кертеп җибәрү - 2015 ел, кулланy - 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ...затларның шэхси эшләрен алып ...сәтелгән вазыйфаларга билгеләп ... тору һәм мондый хезмәткә керү | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018-2024 елларда, ярты елга бер тапкыр | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ...яләү комиссиясе эшчәнлегенең ...анлык җәмгыяте институтларын | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| ... һәм республика законнарында ...иянең нәтиҗәле эшләвен тәэмин | АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| ...рләрнең керемнәре, чыгымнары, ...агыйдәләр нигезендә мәгълүмат | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | | | | - | - | - | - |
| ...әү, урманнарны һәм су саклау ...ыкны җәлеп итү максатларында. ...р кору | АМР Башкарма комитеты АМР җир-мөлкәт палатасы (килешү буенча) | 2016 - 2024 еллар | Су һәм урман законнары өлкәсендә ачыкланган хокук бозулар саны | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - |
| ...ликтын булдырмауга һәм җайга ...ннары таләпләренең үтәлешен | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), Таләпләрне үтәү комиссиясе АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә һәм җайга салуга (килешү буенча) | 2018 - 2024 еллар, квартал саен | Үткәрелгән анализлар/муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми саныннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлешен тикшерү. Мәнфәгатьләр конфликты белән бәйле хокук бозган муниципаль хезмәткәрләр саныннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тартылучылар саны | - | - | - | - | 5 | 5 | 10 | 10 | 10 | 10 | 10 | - | - | - | - |
| | | | | | 2 нчĕ бурыч. Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупция... һәм бетерү, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү... | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| …спертизаны нәтиҗәле уздыруны …теру | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән норматив хокукый актларның аларның проектларын эшләү стадиясендә өлеше-процент | 95 | 96 | 96 | 97 | 97 | 100 | 100 | 100 | 10[illegible] |
| … үткәрү өчен кирәкле шартлар | АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | |
| …торинг үткәрү һәм аларның | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015 - 2024 еллар | Социологик сораштырулар оештыру буенча дәүләт йөкләмәсен үтәүнең тулылыгы - процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | |
| …ы чараларны гамәлгә ашыру …евентив чаралар эшләү өчен | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | |
| … итү: | АМР Советының ММЧ белән эшләү бүлеге (килешү буенча), район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | | |
| … төркемнәреннән социологик | АМР Советы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар, елга кимендә 1 тапкыр | Үткәрелгән социологик сорашып белешүләр саны | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | |

4 нче бурыч Коррупциягә каршы укытуны һәм коррупциягә каршы пропагандалауны активлаштыру, … һәм башка ресурсларны коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| , шулай ук җәмәгатьчелек сроклы махсуслаштырылган | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Коррупциягә каршы торуда катнашучы аерым категория хезмәткәрләрнең, шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләренең һәм башка затларның квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән кыска сроклы махсуслаштырылган семинарлар оештыру һәм үткәрү | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| махсус квалификацияләрен | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018-2024 елларда, ярты елга бер тапкыр | Вазыйфаи бурычларына коррупциягә каршы тору буенча махсуслаштырылган квалификация күтәрүче (кимендә 50%) хезмәткәрләр саны керә. | - | - | - | - | 50 | 70 | 90 | 100 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| н вазыйфаларны белү өчен махсуслаштырылган укытуга | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча); АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2018-2024 елларда, ярты елга бер тапкыр | Муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән һәм махсуслаштырылган укуларны узган муниципаль хезмәткәрләр саны муниципаль хезмәткә беренче тапкыр кергән (кимендә 90 процент) | - | - | - | - | 90 | 90 | 90 | 90 |
| ән җаваплы кадрлар хезмәте законнарының коррупциягә ндагы таләпләре, муниципаль ı кабул итү | АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018-2024 елларда, ярты елга бер тапкыр | Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль районнарда эшләүче иҗтимагый советлар әгъзалары саныннан уздырылган индивидуаль чаралар саны (кимендә 50 %). | - | - | - | - | 50 | 60 | 70 | 80 |
| берләшмәләрне һәм граждан һәм муниципаль оешма ıру | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Башкарма комитеты, АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча), АМР буйсынуындагы | 2015 - 2024 еллар | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль оешмалар өлеше | - | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | 50 | 50 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләр (килешү буенча) | | | | | | | | | | |
| ірда коррупцияне кисәтү<br><br><br><br>МКУ<br>е» МКУ;<br>У;<br><br><br><br><br>ТІ; | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе, (килешү буенча) АМР Башкарма комитеты Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (килешү буенча); АМР җир-мөлкәт палатасы (килешү буенча) | 2016 - 2024 еллар | Җирле үзидарә органнары алдына куелган бурычларны үтәү өчен төзелгән оешмалар саны АМР коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |
| ьәләләрен жайга сала торган | АМР Башкарма комитеты, Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (килешү буенча), АМР Җир-мөлкәт палатасы (килешү буенча) | 2018 ел | Ведомство буйсынуындагы оешмалар саны<br>АМР оешмалары уставларга, ведомство буйсынуындагы оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре белән хезмәт килешүләренә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм жайга салу мәсьәләләрен жайга сала торган нормалар кертелде;<br>Ведомстволар саны<br>җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан мәнфәгатьләр конфликты булу турында бирелгән хәбәрнамәләр; ведомство буйсынуындагылар саны<br>җитәкчеләренең һәм/яисә хезмәткәрләренең мәнфәгатьләре низагын ачыклаган һәм аларны булдырмау һәм/яисә аны жайга салу чаралары күрелгән оешмалар | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 |
| ан мәнфәгатьләр конфликтын<br>лар күрү, шул исәптән әлеге<br>шу таләпләре тарала торган<br>шартнамәләренең таләпләрен | АМР Башкарма комитеты, Алабуга шәһәре Башкарма комитеты (килешү буенча), АМР Җир-мөлкәт палатасы (килешү буенча) АМР мәнфәгатьләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм конфликтын жайга салу комиссиясе (килешү буенча), Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2018-2024 елларда, ярты елга бер тапкыр | Ведомство буйсынуындагы оешмаларның гомуми саныннан уздырылган тикшерүләр саны; мәнфәгатьләр конфликтының ачыкланган/жайга салынган фактлары саны; мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм / яисә аны жайга салу буенча чаралар күрелмәгән өчен җитәкчеләр һәм / хезмәткәрләр саны; | - | - | - | - | 100 | 100 | 100 | 100 |
| ендә плакатлар, коррупциягә | АМР Башкарма комитеты | 2015 - 2024 еллар | Үткәрелгән аңлату чаралары саны<br>конкурслар | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тыру һәм үткәрү, шул исәптән лем бирү мәгариф оешмалары түзеп булмаслык мөнәсәбәт итүгә юнәлдерелгән. | АМР Башкарма комитетының Яшьләр эшләре буенча идарә , ВУЗлар һәм ССУЗлар (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Үткәрелгән аңлату чаралар саны<br>үткәрелгән фәнни-гамәли конференцияләр, очрашулар, дебатлар, форумнар, «түгәрәк өстәлләр» һәм семинарлар саны | 1 | 2 | 3 | 3 | 4 | 5 | 6 | 6 |
| институтлары - муниципаль башка чаралар комплексын, шул исәптән бүләкләр алуга, у максатларында билгеләнгән ру | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), АМР Иҗтимагый оешмалары (килешү буенча). | 2016 - 2024 еллар | Үткәрелгән оештыру чаралары һәм аңлату чаралары саны<br>- | - | - | 1 | 2 | 5 | 5 | 5 | 5 |
| р тарафыннан ришвәт бирүне ак кабул ителә торган үз-үзен шыру. | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе (килешү буенча), ЕМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча), | 2015 - 2024 еллар | Үткәрелгән аңлату чаралар саны<br>- | 10 | 15 | 20 | 25 | 30 | 35 | 40 | 45 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| не һәм таләпләрне үтәмәгән отуны гамәлгә ашыру | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР мәнфәгатьләре конфликтын хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм җайга салу комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча), АМР хокук палатасы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәү буенча үткәрелгән анализлар саны /тикшерүләр | 10 | 20 | 30 | 40 | 50 | 60 | 70 | 80 |
| | | | 5 нче бурыч. Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачык булуын һәм һәркем өч аларның гражданлык җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, коррупциягә каршы активлыкны | | | | | | | | |
| ң җирле үзидарә органнары әмәләренең үтәлешен тәэмин | АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Гражданнарның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты белән канәгать булу дәрәҗәсе, процент | 75 | 75 | 80 | 80 | 90 | 90 | 90 | 90 |
| нан дәүләт һәм муниципаль ы сораштыру юлы белән дә, | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | |
| сын гамәлгә ашыру турында тлар әгъзаларын җәлеп итеп) | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР Иҗтимагый советы, АМР иҗтимагый оешмалары (килешү буенча) | 2018 - 2024 еллар, елга 1 тапкыр | Иҗтимагый фикер алышулар саны | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эптән муниципаль хезмәтләр | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, АМР жирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Тору урыны буенча «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дә, процент.<br><br>Бер хезмәт алу өчен жирле үзидарә органнарында бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләренең мөрәҗәгатьләренең уртача саны | 40 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 | 90 |
| ча «Интернет» мәгълүмат-<br>:арма органнарының рәсми<br>эслау турында» 2013 елның 4<br>Алабуга муниципаль районы | Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча райо башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча), АМР жирле үзидарә органы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | ТР Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларының бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 елның 4 апрелендәге 225 номерлы карары белән расланган законнар һәм таләпләр нигезендә үзенең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итүче ҖҮО өлеше-процент | 60 | 65 | 70 | 75 | 80 | 85 | 90 | 90 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ...да җәмәгатьчелеккә мәгълүмат ... мәсьәләләре буенча районнар ... затлар катнашында үткәреләә ...филактикалау буенча эш өчен | район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча), АМР Советының кадрлар хезмәте (килешү буенча) | 2018 - 2024 еллар, квартал саен | Муниципаль районда коррупциягә каршы эш нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү чаралары саныМуниципаль районда (шәһәр округында) коррупциягә каршы эш нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 |
| ...ция фактлары, аларны кылуга ...аныч телефоннары», «Кайнар | АМР Советы (килешү буенча), АМР Советының ММЧ белән эшләү бүлеге (килешү буенча), АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Дәүләт һәм муниципаль органнар эшчәнлегенең халык өчен ачыклыгын, һәркем өчен ачык булуын тәэмин итүгә, аларның гражданнар җәмгыяте белән элемтәсен ныгытуга, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга, бер елга планлаштырылган гомуми саннан-процент | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| ...ы турында еллык отчетларны ...сайтларда урнаштыру | АМР Советының ММЧ белән эшләү бүлеге (килешү буенча), АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча). Район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| у муниципаль программасын урнаштыру. | район башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, | 2018-2024 еллар, ел саен 1 февральгә кадәр | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы тору муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисапны рәсми сайтның " Коррупциягә каршы тору» бүлегендә урнаштыру. | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 |
| һәм аның нәтиҗәләрен карап нар һәм юридик затларның ңда мәгълүмат мониторингын | АМР Советының ММЧ белән эшләү бүлеге (килешү буенча), АМР Советының хатлар секторы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Мониторинг уздыру вакыты, ай саен | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| ында массакүләм мәгълүмат | АМР коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе (килешү буенча), АМР Советының ММЧ белән эшләү бүлеге (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Мәгълүмат юнәлеше ешлыгы, квартал саен | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| махсус мәгълүмат стендларын | Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе | 2015 - 2024 еллар | Махсус мәгълүмат стендлары өлеше, процентларда | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 6 нчы бурыч Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрс ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| уларны гамәлгә ашырганда тән гамәлгә ашырыла торган лар уздыру, шулай ук сатып а чараларны гамәлгә ашыру | АМР перспективалы социаль-икътисадый үсеш палатасы (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуны гамәлгә ашыру эшчәнлегенең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән җирле үзидарә органнары өлеше, процентларда | 60 | 80 | 85 | 90 | 95 | 100 | 100 | 100 |
| 7 нче бурыч Эшкуарлыкка административ басымны әзлекле рәвештә киметү (бизнес-с | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| н административ киртәләр һәм лай ук эшкуарлар арасында | АМР перспективалы социаль-икътисадый үсеш палатасы (килешү буенча), АМР җирле үзидарә органнары (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Эшкуарлар белән утырыш саны | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| 8 нче бурыч. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хо үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | |
| гълүмати хезмәттәшлек: | Алабуга шәһәр прокуратурасы (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Дәүләт программасында каралган контроль тикшерүләрне гамәлгә ашыру тулылыгы, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| ширганда коррупцион хокук | | | | | | | | | | | |
| ган тыюлар һәм чикләүләрне | | | | | | | | | | | |
| тү субъектлары тарафыннан | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| вазыйфаи затлар структурасы | | | | | | | | | | | |
| нан читләштерү, гаепләләрне кәбәр итү; | | | | | | | | | | | |
| аль контроль органнары белән | | | | | | | | | | | |
| 9 нчы бурыч Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү буенча чараларны кө | | | | | | | | | | | |
| коррупцион куркынычларны тү | Башкаручы АМР комитеты, АМР Советы (килешү буенча), АМР ЖҮИ (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | Татарстан Республикасы социаль-икътисадый мониторинг комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча, үз проблемаларын хәл итү өчен вакыт яисә мөмкинлекләр булмау сәбәпле, коррупция белән алыш - бирешкә керүче муниципаль район халкы өлеше, процент<br>Мөрәҗәгатьләр саны | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| ерү чиратын саклауны тәэмин<br>ан Республикасы мәктәпкәчә | АМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе; | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | | | |
| гражданнар мөрәҗәгатьләрен | АМР Башкарма | 2015 - | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чараны коррупциягэ каршы | комитетының мэгариф идарэсе, Алабуга үзэк район хастаханэсе ДАССУ (килешү буенча) | 2024 еллар | | | | | | | |
| эш комиссиясенең нэтиҗэле җэлеп итү | АМР хэрби комиссариаты (килешү буенча) | 2015 - 2024 еллар | | | | | | | |
| | | | | | | | | 512,45 мең сум. | |

**Файдаланылган кыскартулар исемлеге:**
АМР-Алабуга муниципаль районы
ҖҮИ - Алабуга муниципаль районының җирле үзидарэ органнары
АМР Советы - Алабуга муниципаль районы Советы
АМР ПСИҮП - Алабуга муниципаль районының перспективалы социаль-икътисадый үсеш палатасы
Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьлэр эшлэре, спорт һэм туризм идарэсе;
ММЧ - массакүлэм мэгълүмат чаралары